**ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ**
**АКТАНЫШ МУНИЦИПАЛЬ РАЙОНЫ**
**ЧАЛМАНАРАТ АВЫЛ ЖИРЛЕГЕ**
**БАШКАРМА КОМИТЕТЫ**

423752, Чалманарат авылы, Үзәк ур., 2 нче йорт. Тел 5-32-25
Email: chlm-akt@yandex.ru

**ИСПОЛНИТЕЛЬНЫЙ КОМИТЕТ**
**ЧАЛМАНАРАТСКОГО**
**СЕЛЬСКОГО ПОСЕЛЕНИЯ**
**АКТАНЫШСКОГО МУНИЦИПАЛЬНОГО**
**РАЙОНА**
**РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН**
423752, село Чалманарат, ул. Центральная,
дом 2. Тел 5-32-25
Email: chlm-akt@yandex.ru

# КАРАР

№14 09.07.2025 г.

Татарстан Республикасы Актаныш муниципаль районы Чалманарат авыл җирлеге муниципаль берәмлеге территориясендә кулланылган терекөмешле лампалар туплану урыны булдыру, кулланучыларга аның урнашуы турында мәгълүмат бирү хакында

Россия Федерациясе Хөкүмәтенең 2020 елның 28 декабрендәге 2314 номерлы «Җитештерү һәм куллану калдыкларын тиешенчә җыю, туплау, файдалану, зарарсызландыру, транспортировкалау һәм урнаштыру, гражданнарның гомеренә, сәламәтлегенә, хайваннарга, үсемлекләргә һәм әйләнә-тирә мохиткә зыян китерергә мөмкин булган яктырткыч җайланмалар, электр лампалары белән эш итү кагыйдәләрен раслау турында»гы (2024 елның 14 мартындагы үзгәрешләр белән) карары нигезендә, Актаныш муниципаль районы Чалманарат авыл җирлеге башкарма комитеты

**КАРАР БИРӘ:**

1. Татарстан Республикасы Актаныш муниципаль районы Чалманарат авыл җирлеге территориясендә кулланылган терекөмешле лампаларның туплау урыннарын түбәндәге адрес буенча билгеләргә: Татарстан Республикасы, Актаныш районы, Чалманарат авылы, Узэк р., 2 й.
2. Күпфатирлы йортлардагы урыннарның милекчеләре, яллаучылары, алардан файдаланучылары булган кулланылган терекөмешле лампалар туплау урыннары Россия Федерациясе Хөкүмәтенең 2020 елның 28 декабрендәге 2314 номерлы карары белән расланган җитештерү һәм куллану калдыкларын тиешенчә җыю, туплау, файдалану, зарарсызландыру, транспортировкалау һәм урнаштыру гражданнарның гомеренә, сәламәтлегенә, хайваннарга, үсемлекләргә һәм әйләнә-тирә мохиткә зыян китерергә мөмкин булган яктырткыч җайланмалар, электр лампалары белән эш итү кагыйдәләренең 4 пункты нигезендә билгеләнә.
3. Күпфатирлы йортлардагы файдаланучылар, кулланылган терекемеш лампаларны туплау урыннарын оештыру әлеге күпфатирлы йортларда туплау урыннарын оештыру өчен бүлмәләр булмау сәбәпле, мөмкин түгел дип саный, әлеге карарның 1 пунктында күрсәтелгән терекөмешле лампаларны туплау урыннары шул исәптән милекчеләр, яллаучылар булган терекөмешле лампаларны кулланучылар өчен дә билгеләнгән дип билгеләргә.
4. Татарстан Республикасы Актаныш муниципаль районы Чалманарат авыл җирлеге территориясендә кулланылган терекөмеш лампаларын туплау урыннарының әйләнә-тирә мохитнең федераль дәүләт мәгълүмат системасында урнашуы турында мәгълүмат урнаштыру юлы белән, шулай ук мәгълүмат Татарстан Республикасы Актаныш муниципаль районының рәсми сайтында, Татарстан Республикасы Актаныш муниципаль районы Чалманарат җирле үзидарә органнары биналарында мәгълүмат стендларында урнаштырылуы турында мәгълүмат урнаштыру юлы белән кулланучыларга мәгълүмат бирергә.
5. Әлеге карарны Татарстан Республикасының рәсми хокукый мәгълүматы порталында бастырып чыгарырга һәм Татарстан Республикасы Актаныш муниципаль районының рәсми сайтында «Авыл җирлекләре» бүлегендә урнаштыру юлы белән халыкка җиткерергә.
6. Әлеге карарның үтәлешен тикшереп торуны үз җаваплылыгымда калдырам.

Башкарма комитет җитәкчесе К.С.Ахметов

Исполнительный комитет Чалманаратского сельского поселения